**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 гыйнвар № 22

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен өйрәнү һәм белемнәрне камилләштерү буенча уку курслары турындагы нигезләмәне һәм Татар телен үзләштерү дәрәҗәсен бәяләүне үткәрү тәртибен раслау хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 ел, 8 июль, 1560-XII нче Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен өйрәнү һәм белемнәрне камилләштерү буенча уку курслары турындагы нигезләмәне;

Татар телен үзләштерү дәрәҗәсен бәяләүне үткәрү тәртибен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\22.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 19 гыйнвар, 22 нче
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен өйрәнү һәм белемнәрне камилләштерү буенча уку курслары турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен өйрәнүгә һәм белемнәрен камилләштерүгә хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре өчен, шулай ук татар телен өйрәнергә теләгән гражданнар өчен татар телен укыту курслары оештырыла. Курслар ихтыярый нигездә оештырыла.

Курсларның төп бурычы – тыңлаучыларда лингвистик компетентлык формалаштыру, һөнәри эшчәнлекләре кысаларында татар телен гамәлдә куллануга ирешү, Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллануда тыңлаучыларның коммуникатив мөмкинлекләрен арттыру.

1.2. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алулар, эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә килешү системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән татар телен өйрәнү курсларын ачу өчен нигез булып тора.

1.3. Курсларда белем бирү процессының эчтәлеге мәгариф программамаларында билгеләнә.

1.4. Татар телен курсларда укыту буенча тулы курс 108 академик сәгать тәшкил итә.

1.5. Дәресләр тиешле юнәлеш (профиль) буенча югары белеме, кимендә 3 ел педагогик стажы, беренче яки югары квалификация категориясе булган татар теле һәм әдәбияты укытучылары, шулай ук югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары укытучылары тарафыннан үткәрелә.

1.6. Татар телен өйрәнү курслары үткәрелә торган оешма кирәкле җиһазлар, уку-укыту-методик, белешмә һәм дидактик материал белән тәэмин итә.

## 2. Курсларны оештыру максатлары һәм бурычлары

2.1. Курсларның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен өйрәнүдә халык ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

тыңлаучыларның коммуникатив күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү.

2.2. Курсларда белем бирү процессының төп бурычлары түбәндәгеләр:

күпдәрәҗәлек һәм күпкомпонентлык принциплары буенча татар телендә аралашу өчен әһәмиятле күнекмәләрне эзлекле тәртиптә үстерү (аудирование, сөйләшү, уку һәм язу);

уку-укыту программаларында һәм курслар планнарында билгеләнгән сүзлек һәм грамматика минимумнары, шулай ук көнкүрештә һәм эштә аралашу өлкәләре чикләрендә аралашу чарасы буларак татар телен укыту;

татар телендә хатасыз һәм дөрес итеп документлар төзергә һәм рәсмиләштерергә өйрәтү.

## 3. Курсларда белем бирү процессын оештыру

3.1. Курсларда укыту түбәндәге баскычлар буенча үткәрелә: татар телен белмәүче, начар белүче тыңлаучылар өчен һәм татар телен өйрәнүне дәвам итүчеләр өчен.

3.2. Төркемнәргә бүлү телне фактик белү дәрәҗәсен билгели торган беренче тест нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Уку төркемнәренең сыйдырышлыгы 10 – 15 кеше күләмендә билгеләнә.

3.4. Дәресләрдәге академик сәгать дәвамлылыгы 45 минут тәшкил итә.

3.5. Курсларда уку йомгаклау тесты белән тәмамлана. Курслар тәмамлангач, тиешле оешма тарафыннан телне үзләштерү дәрәҗәсе буенча таныклык бирелә.

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 гыйнвар, 22 нче карары белән расланды

Татар телен үзләштерү дәрәҗәсен бәяләүне үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип татар телен үзләштерү дәрәҗәсен бәяләүне (алга таба – Бәяләү) үткәрү кагыйдәләрен һәм формасын билгели.

2. Бәяләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана торган таләпләр (алга таба – Таләпләр) нигезендә, Россия Федерациясе гражданнары һәм чит ил гражданнарының татар телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү максатларында үткәрелә.

3. Татар теле буенча белемнәр дәрәҗәсен билгеләү телдән (әңгәмә рәвешендә) һәм язмача (тест рәвешендә), шул исәптән компьютер технологияләреннән һәм дистанцион технологияләрдән файдаланып үткәрелә.

4. Бәяләү Татар теле буенча сертификацияләү үзәге (алга таба – Сертификацияләү үзәге) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Бәяләү өчен Сертификацияләү үзәге кимендә 5 кешедән торган тиешле комиссия төзи.

6. Рәис җитәкчелек иткән бәяләү үткәрү буенча комиссия составы «Филология («Татар теле һәм әдәбияты» профиле)» һәм (яки) «Педагогик белем («Туган тел (татар теле) һәм әдәбият» профиле)» әзерлек юнәлешләре буенча югары һөнәри белемнәре булган, профессорлар-укытучылар составына кергән педагогик хезмәткәрләр арасынннан төзелә.

7. Бәяләү вакытында барлыкка килә торган бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү максатында Сертификацияләү үзәге кимендә 5 кешедән торган каршылыклар комиссиясен төзи.

8. Каршылыклар комиссиясе составы «Филология («Татар теле һәм әдәбияты» профиле)» һәм (яки) «Педагогик белем («Туган тел (татар теле) һәм әдәбият» профиле)», «Юриспруденция» әзерлек юнәлешләре буенча югары һөнәри белемнәре булган һәм профессорлар-укытучылар составына кергән педагогик хезмәткәрләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр вәкилләре арасынннан төзелә.

9. Каршылыклар комиссиясенә Бәяләү үткәрү буенча комиссия әгъзалары кертелә алмый.

10. Бәяләү үткәрү расписаниесе һәм дәвамлылыгы аны үткәрүче Сертификацияләү үзәге тарафыннан билгеләнә.

11. Бәяләүдә катнашучы һәр кешегә аерым эш урыны бирелә.

12. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән бәяләүдә катнашучылар өчен эш урыны аларның психофик үсеш үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен һәм сәламәтлек хәлен исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

13. Бәяләүне үтү өчен Россия Федерациясе гражданы яки чит ил гражданы Сертификацияләү үзәгенә язмача яисә электрон рәвештә гариза тапшыра. Гариза формасы Сертификацияләү үзәге тарафыннан раслана һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Сертификацияләү үзәгенең рәсми сайтында урнаштырыла.

14. Сертификацияләү үзәге Бәяләү үткәрүгә кадәр бер атнадан да соңга калмыйча аны үткәрү көне турындагы мәгълүматны һәм тестларның күрсәтмә вариантларын үзенең мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

15. Бәяләү үткәргәнче, Сертификацияләү үзәге Россия Федерациясе гражданына яки чит ил гражданына түбәндәгеләргә мөмкинлек бирә:

Бәяләү үткәрү тәртибе һәм формасы белән танышып чыгарга;

Бәяләү үткәрү мәсьәләләре буенча консультацияләр алырга;

Бәяләүне тестларның күрсәтмә вариантлары буенча мөстәкыйль рәвештә үтәргә һәм аның нәтиҗәләре белән танышырга.

16. Бәяләү үткәрү көнендә, аны үткәрә башлаганчыга кадәр, Бәяләү үткәрү буенча комиссия әгъзасы Бәяләү процедурасын үтүчеләргә инструктаж үткәрә, шулай ук аны үткәрү тәртибе һәм формасы, дәвамлылыгы, нәтиҗәләр белән танышу вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирә.

17. Бәяләү нәтиҗәләре буенча татар телен белүнең түбәндәге дәрәҗәләре билгеләнә ала:

А 1 дәрәҗәсе – элементар дәрәҗә;

А 2 дәрәҗәсе – база дәрәҗә;

В 1 дәрәҗәсе – урта дәрәҗә;

В 2 дәрәҗәсе – уртадан югары дәрәҗә;

С 1 дәрәҗәсе – югары дәрәҗә;

С 2 дәрәҗәсе – телне камил белү дәрәҗәсе.

18. Россия Федерациясе гражданнарына һәм чит ил гражданнарына Бәяләү нәтиҗәләре буенча формасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана торган татар телен белү дәрәҗәсе турындагы таныклык бирелә.